РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
Каргопольское сельского поселения Алькеевского муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Әлки муниципаль районы
Карга авыл жирлеге
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Адрес: 422875, РТ, с. Каргополь, ул. Центральная, 30
тел: : 8 (84346) 77-8-80

Адресы: 422875, РТ, Карга авылы, Узэк ур.,30
факс: 8 (84346) 77-8-80

ПОСТАНОВЛЕНИЕ Карга ав. КАРАР

2025 елның 09 июне № 26

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Карга авыл җирлеге территориясендә йорт хайваннарын йөртү урыннарын билгеләү турында

06.10.2003 елның 131-нче Федераль Законы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында», 27.12.2018 елның 489-нче Федераль Законы «Хайваннар белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында», Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының « Карга авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы таянып, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Карга авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР КАБУЛ ИТӘ:**

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының « Карга авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә йорт хайваннарын йөртү өчен түбәндәге урыннарны билгеләргә:

1.1. Файдаланудагы яисә хуҗа милкендәге җир кишәрлекләре;

1.2. Халык күплəп җыелмый торган авыл җирлеге территориясендә торак сектор һәм җәмәгать урыннары артындагы урыннарда, борындыкларда һәм тезгендә аларның хуҗалары күзәтүе астында:

-Карга авылының көньяк-көнчыгыш өлешендә Карга авылы яр буе урамыннан 100 метр ераклыкта

-Карга авылының көньяк-көнбатыш өлешендә, Камай урамыннан 200 метр ераклыкта .

Бу территорияләрдә «йорт хайваннарын йөртү»дигән язулы табличкалар урнаштырырга.

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru хәм Әлки муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Әлки муниципаль районының
Карга авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе Р.И. Гинанова

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАРГОПОЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ